МИНИСТЕРСТВО ЦИФРОВОГО РАЗВИТИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО УПРАВЛЕНИЯ, ИНФОРМАЦИОННЫХ ТЕХНОЛОГИЙ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕН ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ ҮСТЕРҮ, МӘГЪЛҮМАТ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.08.2024 Казан ш. № п/159

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2022 елның 17 августындагы п/217 номерлы боерыгы белән расланган Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының «Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 17 августындагы п/217 номерлы боерыгы белән расланган Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.6.1.2 пунктының 3 пунктчасында «(алга таба – 273-ФЗ номерлы федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

2.6.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.6. Әгәр мөрәҗәгать итүчеләрнең исәбе финанслануы Татарстан Республикасы бюджет ассигнованиеләре хисабына гамәлгә ашырыла торган урыннар санынннан артып китсә, белем бирү оешмасы укырга керүче затларның

алынган белем турында тапшырылган документларда һәм (яки) алынган белем турында һәм квалификация турындагы документларда күрсәтелгән төп гомуми яки урта гомуми белем алу буенча мәгариф программасын үзләштерү нәтиҗәләрен, укырга керү сынауларының нәтиҗәләрен (булган очракта), индивидуаль казанышларның алар турындагы белешмәләрне укырга керә торган зат укырга кабул иткәндә тапшырырга хокуклы булган нәтиҗәләрен исәпкә ала, шулай ук, 273-ФЗ номерлы федераль законның 68 статьясында башкача каралмаган булса, 273-ФЗ номерлы федераль законның $71^1$ статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар белән максатчан укыту турында шартнамә булу-булмавын исәпкә ала.

273-ФЗ номерлы федераль законның 71 статьясындагы 7 өлешенең 1-13 пунктларында күрсәтелгән затларга керү сынауларын уңышлы узу (алар уздырылган очракта) шарты белән һәм башка бертигез шартларда урта һөнәри белемнең уку-укыту программалары буенча уку йортына укырга керү өчен өстенлекле хокук бирелә.

273-ФЗ номерлы федераль законның $71^1$ статьясының 5 өлешендә күрсәтелгән затларга, 273-ФЗ номерлы федераль законның $71^1$ статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар белән максатчан укыту турында шартнамәнең булуы хакында тапшырылган документларда һәм (яисә) квалификация турында документларда күрсәтелгән төп гомуми яисә урта гомуми белем бирү уку-укыту программасын әлеге затлар тарафыннан үзләштерү нәтиҗәләренә бәйле рәвештә урта һөнәри белем бирү программалары буенча уку йортына беренче чиратта укырга керү хокукы бирелә.».

Министр А.Р. Хәйруллин